ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш, Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш., Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 27 от «02» 02 2021 г.

«Кулланучылар кооперациясе тарафыннан Мамадыш шәһәреннән 11 км дан артык ераклыкта урнашкан аз халыклы торак пунктларга көнкүреш кирәк- яраклары китерү белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Мамадыш муниципаль район бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 1593 нче санлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгының 2021 елның 13 январендәге № 09/13-09/49 хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджетыннан кулланучылар кооперациясе оешмаларының Мамадыш шәһәреннән 11 км ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү максатларында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазифаларын башкаручы тарафыннан 2017 елның 22 декабрендә кабул ителгән 1593 нче санлы карары белән расланган «Кулланучылар кооперациясе тарафыннан Мамадыш шәһәреннән 11 км дан артык ераклыкта урнашкан аз халыклы торак пунктларга көнкүреш кирәк- яраклары китерү белән бәйле чыгымнарны каплау өчен Мамадыш муниципаль район бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге шартлы эчтәлектәге 2.3. пунктын өстәргә:
«Салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмә бирү чараларын алу шарты буларак каралучы».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче И.М.Дәрҗеманов

0000010717